КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 март г.Казань № 281

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 16 май, 326 нчы карары белән Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 16 май, 326 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 август, 619 нчы; 2009 ел, 15 июнь, 394 нче; 2011 ел, 20 декабрь, 1021 нче; 2013 ел, 11 июнь, 398 нче; 2016 ел, 27 июнь, 443 нче; 2016 ел, 27 июль, 515 нче; 2016 ел, 5 декабрь, 891 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 806 нчы; 2019 ел, 9 август, 660 нчы; 2020 ел, 24 февраль, 131 нче; 2020 ел, 6 март, 172 нче; 2021 ел, 14 гыйнвар, 9 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә, аларны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 16 май, 326 нчы карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 март, 281 нче карары редакциясендә)

## Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләре

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Кагыйдәләр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар (алга таба – сертификат) бирү һәм реализацияләү тәртибен билгели.

2. Сертификат күпбалалы гаиләнең Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын алу хокукын раслый торган исемле таныклык булып тора.

Сертификат кыйммәтле кәгазь булып тормый.

3. Сертификатның гамәлдә булу срогы сертификатта күрсәтелә һәм ул бирелә торган көннән исәпләнелә һәм тугыз ай тәшкил итә.

4. Сертификат алу хокукына җирле үзидарә органнарында социаль наем шартнамәсе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торучы, ата-анасы белән яши торган һәм үз гаиләләрен булдырмаган биш һәм аннан да күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләр (алга таба – күпбалалы гаиләләр) ия (күпбалалы гаиләнең үз гаиләсен булдырган балаларына никахлашкан яки үз баласы (балалары) булган балигъ булмаган балалар керә).

5. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары кысаларында торак урын алу хокукы бер тапкыр бирелә.

6. Бирелә торган торак урынның гомуми мәйданы күләме сертификат бирелә торган датага Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан исәпләнелә һәм сертификатта күрсәтелә.

7. Торак урынның гомуми мәйданы нормативы һәр гаилә әгъзасына 18 кв.метр күләмендә билгеләнә.

8. Бирелә торган торак урынның гомуми мәйданы, күпбалалы гаилә били торган торак урынның гомуми мәйданын тотып калып (били торган торак урын санитария нормаларына һәм яшәү кагыйдәләренә туры килгән очракта), бу Кагыйдәләрнең 7 пунктында билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданы нормативыннан чыгып билгеләнә.

Күпбалалы гаилә һәм (яки) гаиләнең аерым әгъзалары тарафыннан аларның милек хокукында булган торак урын (торак урыннар) йә әлеге гражданнарның торак

урынга уртак милек хокукындагы өлеше алынган очракта, бирелә торган торак урынның гомуми мәйданы күләме бу Кагыйдәләрнең 7 нче пунктында күрсәтелгән норматив буенча билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданы һәм күпбалалы гаилә тарафыннан социаль наем шартнамәләре, социаль файдаланудагы торак фондның торак урыннары наем шартнамәләре буенча биләнә торган һәм (яки) күпбалалы гаиләнең һәм (яки) аерым гаилә әгъзаларының милек хокукында булган торак урыннарның (били торган торак урыннар санитария нормаларына һәм яшәү кагыйдәләренә туры килгән очракта) һәм алынган торак урынның (торак урын милекчеләренең килешүендә билгеләнгән яки торак урынга уртак милек хокукындагы өлешләренә пропорциональ исәпләнгән, аерым гаилә әгъзасына туры килә торган торак урынга милек хокукындагы өлешнең) кушылган гомуми мәйданы арасындагы аерма буларак билгеләнә. Әлеге граждан-хокукый алыш-бирешләрдә күпбалалы гаиләгә сертификат бирелә торган ел алдындагы биш ел исәпкә алына.

## II. Сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең исемлекләрен төзү тәртибе

9. Планлаштырыла торган елда сертификат бирү эшен оештыру максатларында җирле үзидарә органнары планлаштырыла торган елга сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең исемлекләрен төзи.

10. Планлаштырыла торган елга сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең исемлегенә кертү өчен түбәндәге документлар кирәк:

1) планлаштырыла торган елга сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең исемлегенә кертү турында гариза (торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә торучы күпбалалы гаиләдәге ата-ананың берсе (алга таба – гариза бирүче) тарафыннан кул куела, ике нөсхәдә бирелә, шуларның берсе, гаризаны кабул итү датасы һәм теркәлә торган документлар күрсәтелеп, гариза бирүчегә кире кайтарыла);

2) гариза бирүченең һәм һәр гаилә әгъзасының шәхесен таныклый торган документлар (паспорт, туу турында таныклык) күчермәләре;

3) гариза бирүченең гаилә составын раслый торган документларның («Граждан хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык йә гаилә әгъзасы итеп тану турында, уллыкка (кызлыкка) алу турында суд карары (билгеләмәсе)) күчермәләре;

4) күпбалалы гаиләдә балигъ булган балаларның гаилә хәле турында һәм күпбалалы гаиләдә балигъ булган балаларның үз балалары булу (булмау) турында граждан хәле актларын теркәү органының белешмә кәгазе;

5) торак урында яшәү урыны буенча яшәүче гражданнар санын раслый торган мәгълүматлар;

6) «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән органнар тарафыннан гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының торак урыннарга милек хокуклары булуы (булмавы) турында, шулай ук бу пунктта каралган до-

кументлар тапшырылган датага кадәр биш елдан ким булмаган чорга алардан читләшү буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыру турында мәгълүматлар бирелә торган документлар (документлардан өземтәләр);

7) гариза бирүченеке һәм (яки) аның гаилә әгъзаларыныкы булган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокукы теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документның (документларның) күчермәсе;

8) гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары били торган торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларның (ордер, торак урын бирү турында карар, социаль наем шартнамәсе яки башка документлар) күчермәләре;

9) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу (булмау) турында мәгълүматлар;

10) бу Кагыйдәләрнең 1 – 3 нче кушымталарында бирелгән формаларда шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

Бу пунктның 1, 2, 7, 10 пунктчаларында күрсәтелгән документлар гражданнар тарафыннан планлаштырыла торган ел алдындагы елның 1 маеннан 1 августына кадәрге чорда тапшырыла.

Бу пунктның 3 пунктчасында («Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 3, 3.1 һәм 12 пунктчаларында каралган, гражданнар тарафыннан бирелә торган документлардан тыш), 4 – 6, 8, 9 пунктчаларында күрсәтелгән документлар гражданнар тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылырга мөмкин, ә әлеге документлар тапшырылмаган очракта, җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге документлар белән законнар нигезендә эш итә торган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә соратып алына.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга яки, төп нөсхәсен күрсәтеп, тапшырылырга тиеш.

11. Бу Кагыйдәләрнең 10 пунктында күрсәтелгән, тапшырылган документлар нигезендә җирле үзидарә органнары барлык кирәкле документлар белән гариза кергән көннән 30 көн эчендә аларны тикшерү эшен оештыра.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча күпбалалы гаиләнең бу Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе (туры килмәве) турында һәм планлаштырыла торган елга сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең исемлегенә кертү яки кертүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Планлаштырыла торган елга сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең исемлегенә кертү турында йә кертүдән баш тарту турында (баш тарту нигезләрен күрсәтеп) кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә карар кабул ителгән көннән өч көн эчендә язма рәвештә хәбәр ителә.

12. Планлаштырыла торган елга сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләр исемлегенә кертүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) бу Кагыйдәләрнең 10 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы яки тулысынча тапшырылмавы;

2) тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

3) Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчасы исәбеннән бирелгән субсидиядән файдаланып, торак шартларын яхшырту (торак урын алу) хокукының элегрәк гамәлгә ашырылуы;

4) бу Кагыйдәләрнең 10 пунктында каралган документлар бирелә торган датага күпбалалы гаиләнең бу Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

5) «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы нигезендә күпбалалы гаиләнең яңадан теркәлмәве.

13. Планлаштырыла торган елга сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең исемлегенә кертү турындагы гариза белән кабат мөрәҗәгать итү планлаштырыла торган ел алдындагы елның 1 маеннан 1 августына кадәрге срокта бу Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы 1, 2, 5 пунктчаларында күрсәтелгән баш тарту нигезләре бетерелгәннән соң рөхсәт ителә.

14. Җирле үзидарә органнары ел саен, 1 октябрьгә кадәр, бу Кагыйдәләрнең 4 нче кушымтасындагы форма буенча планлаштырыла торган елга сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең исемлекләрен төзи һәм аларны Министрлыкка тапшыра.

Күпбалалы гаиләне исемлеккә керткән вакытта ул бу Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килергә тиеш.

Исемлекләр шул ук хронологик тәртиптә – күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак җирле үзидарә органнарында исәпкә куелган тәртибендә формалаштырыла.

15. Министрлык ел саен, 25 октябрьгә кадәр, җирле үзидарә органнарыннан алынган исемлекләр нигезендә бу Кагыйдәләрнең 5 нче кушымтасындагы форма буенча планлаштырыла торган елга Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлеген төзи һәм раслый, аны җирле үзидарә органнарына җиткерә.

Җыелма исемлек шул ук хронологик тәртиптә – күпбалалы гаиләләрне җирле үзидарә органнарында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую тәртибендә формалаштырыла.

Бер үк көнне исәпкә куелган күпбалалы гаиләләр Җыелма исемлектә алфавит тәртибендә күрсәтелә.

Күпбалалы гаиләләрне расланган Җыелма исемлеккә өстәмә рәвештә кертү рөхсәт ителми.

16. Җирле үзидарә органнары Җыелма исемлек расланган көннән 10 көн эчендә Министрлыкның таләбе буенча Җыелма исемлеккә кертелгән гариза бирүчеләрнең түбәндәге документларны үз эченә алган исәпкә алу эшләренең билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләрен тапшыра:

1) бу Кагыйдәләрнең 10 пунктында күрсәтелгән документлар;

2) җирле үзидарә органының гариза бирүчене торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую турында карары;

3) күпбалалы гаиләнең «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның

аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы нигезендә яңадан теркәлүе турында белешмә кәгазе;

4) җирле үзидарә органының гариза бирүчене планлаштырыла торган елга сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең исемлегенә кертү турындагы карары.

Исәпкә алу эшенең тулы булмаган документлар пакеты аны тапшырган көннән 10 көн эчендә эшләп бетерү өчен Министрлык тарафыннан җирле үзидарә органына кире кайтарыла.

Җирле үзидарә органнары исәпкә алу эшенең тулы булмаган документлар пакеты алынган көннән биш көн эчендә Министрлык тарафыннан кире кайтарылган исәпкә алу эшләрен бу пунктта билгеләнгән таләпләр нигезендә эшләп бетерү эшен оештыра һәм аларны Министрлыкка кабат җибәрә.

## III. Сертификатлар бирү тәртибе

17. Министрлык ел саен, 1 декабрьгә кадәр, тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында бу Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә каралган акчалар чикләрендә бу Кагыйдәләрнең 6 нчы кушымтасындагы форма буенча планлаштырыла торган елда сертификатлар алучы күпбалалы гаиләләр исемлеген (алга таба – Алучылар исемлеге) һәм бу Кагыйдәләрнең 7 нче кушымтасындагы форма буенча шул ук елда сертификатлар алу резервына кертелгән күпбалалы гаиләләр исемлеген (алга таба – Резерв исемлек) төзи һәм алар расланган көннән 10 көн эчендә исемлекләрне җирле үзидарә органнарына һәм «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә махсуслаштырылган оешмага (алга таба – махсуслаштырылган оешма) җибәрә.

Резерв исемлеккә кертелгән күпбалалы гаиләләрнең саны сертификатлар алучы күпбалалы гаиләләрнең саныннан өч тапкырдан да артык булмаска тиеш.

Алучылар исемлеге һәм Резерв исемлек шул ук хронологик тәртиптә – күпбалалы гаиләләрне җирле үзидарә органнарында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую тәртибендә формалаштырыла.

Алучылар исемлеге шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пунктында билгеләнгән беренче чиратта торак белән тәэмин итү квотасын исәпкә алып төзелә.

18. Алучылар исемлегенә һәм Резерв исемлеккә кертүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) планлаштырыла торган ел алдындагы елның 20 ноябренә кадәрге срок эчендә бу Кагыйдәләрнең 16 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы яки тулысынча тапшырылмавы;

2) тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

3) Министрлык тарафыннан Алучылар исемлеге һәм Резерв исемлек төзелгән вакытта күпбалалы гаиләнең бу Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән таләпләргә

туры килмәве.

Министрлык планлаштырыла торган ел алдындагы елның 1 декабренә кадәр күпбалалы гаиләне Алучылар исемлегенә яки Резерв исемлеккә кертүдән баш тарту турында җирле үзидарә органына, баш тарту нигезләрен күрсәтеп, язма рәвештә хәбәр итә.

19. Министрлык планлаштырыла торган елның 1 апреленә кадәр бу Кагыйдәләрнең 16 пунктында күрсәтелгән, тапшырылган документлар нигезендә сертификатларны рәсмиләштерә һәм аларны күпбалалы гаиләләргә тапшыру өчен җирле үзидарә органнарына җибәрә.

20. Сертификат алу өчен гариза бирүче җирле үзидарә органына түбәндәге документларны тапшыра:

1) бу Кагыйдәләрнең 8 нче кушымтасындагы форма буенча гариза;

2) гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документлар.

21. Сертификатлар тапшыруны гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне соратып ала:

1) торак урында яшәү урыны буенча яшәүче гражданнарның санын раслый торган мәгълүматларны;

2) күпбалалы гаиләдәге балигъ булган балаларның гаилә хәле турында һәм күпбалалы гаиләдәге балигъ булган балаларның үз балалары булуы (булмавы) турында граждан хәле актларын теркәү органының белешмә кәгазен;

3) «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән органнар тарафыннан гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының торак урыннарга милек хокуклары булуы (булмавы) турында, шулай ук бу пунктта каралган документлар тапшырылган көнгә кадәр кимендә биш ел элек алардан читләшү буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыру турында мәгълүматлар бирелә торган документларны (документлардан өземтәләр);

4) гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары били торган торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларның (шартнамә, ордер, торак урын бирү турында карар һәм башка документлар) күчермәләрен.

Гражданнар бу пунктта күрсәтелгән документларны үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.

22. Җирле үзидарә органы бу Кагыйдәләрнең 20, 21 пунктларында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматларны тикшерү эшен оештыра һәм аларны Министрлыкка җибәрә.

Бу Кагыйдәләрнең 20, 21 пунктларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган яки тулысынча тапшырылмаган яисә сертификат рәсмиләштерелгән вакытта күпбалалы гаиләнең балигъ булган балалары статусы үзгәргән яки гаризадагы һәм (яки) документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы ачыкланган очракта, сертификат бирелми.

Җирле үзидарә органының сертификат бирүдән баш тарту турындагы карары ул кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Министрлыкка һәм гариза бирүчегә җибәрелә.

Министрлык, җирле үзидарә органының сертификат бирүдән баш тарту турындагы карарын алганнан соң, өч көн эчендә Министрлыкның боерыгы нигезендә рәсмиләштерелгән сертификатны гамәлдән чыгара.

23. Җирле үзидарә органнары сертификатлар алынган көннән 14 көн эчендә аларны сертификатлар алучы күпбалалы гаиләләргә тапшыра. Күпбалалы гаиләнең сертификат алу факты бу Кагыйдәләрнең 9 нчы кушымтасындагы форма буенча алып барыла торган бирелгән сертификатларны исәпкә алу кенәгәсендә сертификат алучы һәм гаилә әгъзаларының барлык балигъ булган затлары имзасы белән раслана.

24. Алучылар исемлегенә кертелгән күпбалалы гаиләләргә бирергә дип карала торган сертификатлар нинди дә булса сәбәпләр аркасында калган очракта, алар бу Кагыйдәләрнең 19 – 22 пунктларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокта Резерв исемлеккә кертелгән күпбалалы гаиләләргә рәсмиләштерелергә һәм тапшырылырга тиеш.

25. Рәсмиләштерелгән яки бирелгән сертификатны алмаштыруны таләп иткән хәлләр булганда, ул Министрлык тарафыннан сертификатны алмаштыру турында гариза алынган көннән 30 көн эчендә алмаштырыла. Рәсмиләштерелгән яки бирелгән сертификатны алмаштыруны таләп иткән хәлләргә түбәндәгеләр керә: сертификатны югалту (урлау) яки бозу һәм торак урын бирү шартнамәсен төзү өчен аны махсуслаштырылган оешмага билгеләнгән срокта тапшыру мөмкинлеген бирмәгән нигезле сәбәпләр.

Сертификат хуҗасы вафат булган очракта, гаиләнең балигъ булган башка әгъзаларының нотариаль таныкланган ышанычнамәсе нигезендә эш итүче аның гаилә әгъзасы Министрлыкка, үлем турындагы таныклыкның һәм сертификатның күчермәсен теркәп, сертификатны алмаштыру турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Сертификат хуҗасының гаилә әгъзасы вафат булган очракта, сертификат хуҗасы Министрлыкка, гаилә әгъзасының үлеме турындагы таныклык күчермәсен һәм сертификат күчермәсен теркәп, сертификатны алмаштыру турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

26. Бу Кагыйдәләрнең 25 пунктында күрсәтелгән очракларда, алмаштыру юлы белән бирелгән сертификатның гамәлдә булу срогы сертификатта күрсәтелә торган аны биргән көннән исәпләнелә һәм тугыз ай тәшкил итә.

27. Сертификат алыштырылган очракта, Министрлык яңа сертификатның югары уң почмагында түбәндәге эчтәлекле билге ясый: « _________ серияле, _________ номерлы сертификатка алмашка бирелә».»;

28. Җирле үзидарә органнары бирелгән сертификатлар реестрын алып бара.

29. Министрлык бирелгән сертификатларның бердәм реестрын төзи һәм алып бара һәм аларны махсуслаштырылган оешмага җибәрә.

## IV. Сатып алына торган торак урынга түләү тәртибе

30. Сертификат хуҗасы сертификат алынган көннән 14 көн эчендә аны махсуслаштырылган оешма тарафыннан расланган форма буенча торак урын бирү шартнамәсен төзү өчен махсуслаштырылган оешмага тапшыра, шулай ук Министрлык тарафыннан расланган форма буенча торак урынны сайлап алу турында Министрлыкка гариза җибәрә.

31. Махсуслаштырылган оешма һәм сертификат хуҗасы арасында килешү буенча сертификатта күрсәтелгән гомуми мәйдан күләменнән артып киткән гомуми мәйданлы торак урын, гомуми мәйданның аермасы өчен түләп, үз һәм (яки) заем (кредит) акчасын файдаланып бирелергә мөмкин.

32. Күпбалалы гаиләгә бирелә торган торак урын (урыннар) сертификат хуҗасы гаиләсендәге һәр әгъзаның гомуми милкенә рәсмиләштерелә. Ике һәм аннан күбрәк торак урыннар бирелгәндә, әлеге торак урыннарга милек хокукы гаилә әгъзаларының килешүләре буенча рәсмиләштерелә.

33. Махсуслаштырылган оешма сертификат хуҗасы белән торак урын бирү шартнамәсе төзелгән көннән 10 көн эчендә Министрлыкка сертификатка түләү өчен заявка җибәрә.

Сертификат өчен түләү суммасы сертификатта күрсәтелгән гомуми мәйдан күләменнән һәм сертификатны рәсмиләштерү датасына гамәлдә булган, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы белән раслана торган Татарстан Республикасы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар кыйммәтеннән чыгып билгеләнә.

34. Министрлык сертификат хуҗасының торак урын сайлау турындагы гаризасын һәм заявкасын алган көннән 10 көн эчендә махсуслаштырылган оешма счетына сертификатка түләү өчен акча күчерә.

35. Муниципаль берәмлек территориясендә махсуслаштырылган оешма тарафыннан төзелеше финансланган торак урыннар булмаган очракта, күпбалалы гаиләләр, махсуслаштырылган оешма белән килештереп, бүтән муниципаль берәмлек территориясендә махсуслаштырылган оешма тарафыннан төзелеше финансланган торак йортлардагы торак урынны сайлап алу хокукын ала.

36. Махсуслаштырылган оешма сертификат өчен түләнелгән вакыттан 14 көн эчендә Министрлыкка һәм җирле үзидарә органнарына, сатып алынган торак урынның урнашу урынын, аның мәйданын һәм кыйммәтен күрсәтеп, түләнгән сертификатларны һәм торак шартларын яхшырткан сертификатлар хуҗалары исемлекләрен җибәрә.

37. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә бу Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән, торак урын бирү хокукыннан файдаланган гражданнар турында Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә мәгълүмат бирүне тәэмин итә.

38. Бу Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән гражданнарга бирелгән торак урыннарның гомуми мәйданы күләмнәре турында һәм социаль ярдәм күрсәтү чаралары хакында мәгълүмат Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә алынырга мөмкин.

39. Махсуслаштырылган оешма тарафыннан Министрлыкка бу Кагыйдәләрнең 36 пунктында каралган тәртиптә җибәрелгән сертификатлар Министрлыкта өч ел сакланырга тиеш.

Махсуслаштырылган оешмага бу Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм

срокларда кертелмәгән сертификатлар гамәлдән чыгарылган дип санала.

40. Махсуслаштырылган оешмага бу Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда сертификатын тапшырмаган сертификат хуҗасы җирле үзидарә органында социаль наем шартнамәсе буенча торак шартларын яхшырту өчен баскан чиратын саклый.

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә 1 нче кушымта

Форма

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында
ГАРИЗА
(кулдан тутырыла)

Мин, ________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, теркәлү адресы __________________________________________,
телефон номеры (электрон почта адресы) ______________________________________________,
шәхесне раслый торган документ __________________________________________________
(документ исеме, номеры,
___________________________________________________________________________________,
документны бирү датасы һәм биргән орган турында мәгълүматлар)
торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларында катнашу максатларында _________________________________________________________________
(җирле үзидарә органы, бүлекчә исеме,
___________________________________________________________________________________,
ИНН, мәгълүмат ресурслары турында мәгълүматлар)
урнашу адресы: ______________________________________________________________________,
шәхси мәгълүматларымны, атап әйткәндә _____________________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан эшкәртүгә
___________________________________________________________________________________,
ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеген күрсәтергә)
эшкәртүгә, ягъни «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне кылуга ризалык бирәм.

Бу ризалык аңа кул куйган көннән язма рәвештә кире алган көнгә кадәр гамәлдә.

20___ елның «____» _____________

________________ ________________________________________________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә 2 нче кушымта

Форма

Үндүрт яше тулмаган балигъ булмаган зат исеменнән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (кулдан тутырыла)

Мин, ______________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, теркәлү адресы ____________________________________________,
телефон номеры (электрон почта адресы) _______________________________________________,
шәхесне раслый торган документ _________________________________________________________
(документ исеме, номеры,
________________________________________________________________________________________,
документны бирү датасы һәм биргән орган турында мәгълүматлар)
________________________________________________________________________________________,
(балигъ булмаган баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

туган елы ________________, туу турында таныклыгы ________________________________________
(датасы, ае һәм елы) (таныклыкның сериясе һәм номеры,
________________________________________________________________________________________,
таныклык кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
яшәү адресы ______________________________________________________________________________,
(балигъ булмаган баланың теркәлү адресы урыны)
законлы вәкиле буларак эш итүчесе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларында катнашу максатларында ____________________________________
(җирле үзидарә органы, бүлекчә исеме,
________________________________________________________________________________________,
ИНН, мәгълүмат ресурслары турында мәгълүматлар)
урнашу адресы: ____________________________________________________________________________,
_______________________________________________________________________________________ ның
(балигъ булмаган баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
шәхси мәгълүматларын, атап әйткәндә ___________________________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан эшкәртүгә
________________________________________________________________________________________,
ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеген күрсәтергә)
эшкәртүгә, ягъни «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне кылуга ризалык бирәм.

Бу ризалык аңа кул куйган көннән язма рәвештә кире алган көнгә кадәр гамәлдә.

20___ елның «____» _____________

Ата-ана (законлы вәкил) _________________ ______________________________________________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

Искәрмә. Гаризага вәкилнең балигъ булмаган зат исеменнән эш итү вәкаләтен раслый торган документ күчермәсен теркәргә кирәк.

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә 3 нче кушымта

Форма

Ундүрт яше тулган балигъ булмаган зат исеменнән
шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә
ризалык
(кулдан тутырыла)

Мин, ______________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, туган елы _________________, теркәлү адресы ____________
(датасы, ае һәм елы)
______________________________ шәхесне раслый торган документ __________________________
(документ исеме, номеры,
_______________________________________________________________________________________,
документны бирү датасы һәм биргән орган турында мәгълүматлар)
___________________________________________________________________ ның ризалыгы белән
(законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
шәхесне раслый торган документ ____________________________________________________
(документ исеме, номеры,
_______________________________________________________________________________________,
документны бирү датасы һәм биргән орган турында мәгълүматлар)
теркәлү адресы ________________________________________________________________________,
телефон номеры (электрон почта адресы) _________________________________________________,
торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларында катнашу максатларында ______________________________________________________________
(җирле үзидарә органы, бүлекчә исеме,
_______________________________________________________________________________________,
ИНН, мәгълүмат ресурслары турында мәгълүматлар)
урнашу адресы: ________________________________________________________________________,
шәхси мәгълүматларымны, атап әйткәндә _________________________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан эшкәртүгә
_______________________________________________________________________________________,
ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеген күрсәтергә)
эшкәртүгә, ягъни «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне кылуга ризалык бирәм.

Бу ризалык аңа кул куйган көннән язма рәвештә кире алган көнгә кадәр гамәлдә.

20___ елның «____» _____________

_____________________________ _________________________________________________________
(балигъ булмаган зат имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

Ризамын _____________________________________________________________ _________________
(законның вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)

Искәрмә. Гаризага балигъ булмаган зат вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсен теркәргә кирәк.

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә 4 нче кушымта

Форма

«Раслыйм»
Татарстан Республикасының
_______________________________ башлыгы
(муниципаль берәмлек исеме)

20__ ел, «____» ___________

20___ елга Татарстан Республикасының ____________________________________________ буенча
(муниципаль берәмлек исеме)
сертификат алу хокукына ия күпбалалы гаиләләр
исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Туганлык мөнәсәбәтләре (гаилә составы), кеше | Туган көне, ае, елы | Адресы | Паспорт мәгълүматлары | | | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куюны раслый торган документ | | Булган мәйданы, кв.метр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | сериясе, номеры | бирү датасы | кем биргән | датасы | документ номеры | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә 5 нче кушымта

Форма

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
20___ ел, «____» ____________

20__ елга Татарстан Республикасында
күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Туганлык мөнәсәбәтләре (гаилә составы), кеше | Туган көне, ае, елы | Адресы | Паспорт мәгълүматлары | | | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куюны раслый торган документ | | Булган мәйданы, кв.метр | Исәпкә кую органы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | серияse, номеры | бирү датасы | кем биргән | датасы | документ номеры | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә 6 нчы кушымта

Форма

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры
______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
20___ ел, «____» ____________

20__ елга Татарстан Республикасында
сертификатлар алучы күпбалалы гаиләләр исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Гаилә составы), кеше | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую датасы | Торак йортның булган (һәм (яки) читләштерелгән) гомуми мәйданы, кв.метр | Гомуми торак мәйданының социаль нормасы, кв.метр | Исәпкә кую органы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә 7 нче кушымта

Форма

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

___________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
20___ ел, «____» ____________

20__ елга Татарстан Республикасында
сертификатлар алу өчен резервка кертелгән күпбалалы гаиләләр исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Гаилә составы, кеше | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую датасы | Торак йортның булган (һәм (яки) читләштерелгән) гомуми мәйданы, кв.метр | Гомуми торак мәйданының социаль нормасы, кв.метр | Исәпкә кую органы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә
8 нче кушымта

Форма

______________________________
(дәүләт хакимиятенең башкарма органы)
______________________________ җитәкчесенә
______________________________
(почта адресы)
________________ адресы буенча яшәүче
граждан ________________________________,
(фамилиясе, исеме,
______________________________
атасының исеме (соңгысы – булганда))

Гариза

Миңа, ______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
паспорт ________________________, ________ елның «_____» ____________нда (ндә) _____________
______________________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,
________________________________________________________________ территориясендә торак белән
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме)
тәэмин итү өчен сертификат бирүегезне үтенәм.

Гаилә составы:
хатыны (ире) ______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының (соңгысы – булганда), туган көне)
паспорты ____________________, ________ елның «_____» ____________нда (ндә) _________________
______________________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,
__________________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________ адресы буенча яши;
балалары: ___________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)
паспорты (туу турында таныклыгы) __________________________________________, ________ елның
«_____» ____________нда (ндә) __________________________________________ тарафыннан бирелгән,
______________________________________________________________________ адресы буенча яши;
_________________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)
паспорты (туу турында таныклыгы) __________________________________________, ________ елның
«_____» ____________нда (ндә) __________________________________________ тарафыннан бирелгән,
______________________________________________________________________ адресы буенча яши;
_________________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)
паспорты (туу турында таныклыгы) __________________________________________, ________ елның
«_____» ____________нда (ндә) __________________________________________ тарафыннан бирелгән,
______________________________________________________________________ адресы буенча яши;
_________________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)

паспорты (туу турында таныклыгы) ______________________________________, _______ елның «_____» ___________нда (ндә) ___________________________________ тарафыннан бирелгән, ____________________________________________________________________ адресы буенча яши;

_____________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)

паспорты (туу турында таныклыгы) ___________________________________, _______ елның «_____» ___________нда (ндә) _____________________________________ тарафыннан бирелгән, ____________________________________________________________________ адресы буенча яши.

Моннан тыш, минем белән башка гаилә әгъзалары да яши:

_____________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)

паспорты _________________________, _______ елның «_____» _____________нда (ндә) ________ __________________________________________________________________ тарафыннан бирелгән.

___________________________________________________________________________ нигезендә
(норматив акт исеме)

_____________________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән

_________________________________________________________________ категориясенә карыйм,
торак урын алу хокукына ия гражданнар категориясе исеме)

торак шартларын яхшыртуга (торак урыннар алуга) мохтаҗ дип танылдым һәм _________ елның «__» _________ нан(нән) ____________________________________________________________
(исәпкә кую урыны)

______________________________________________________________________ чиратта торам.

________________ номерлы исәпкә алу эше.

I. Хәзерге вакытта минем һәм минем гаилә әгъзаларымның Россия Федерациясе территориясендә даими яшәү өчен торак урыннары юк (бар).
(кирәк булмаганын сызарга)

Минем һәм (яки) минем гаилә әгъзаларым социаль наем шартнамәләре буенча яшәгән һәм (яки) милек хокукында минеке һәм (яки) минем гаилә әгъзаларымныкы булган торак урыннар булу турында мәгълүматлар:

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Торак урыны булган затның сертификат алучы белән туганлык мөнәсәбәтләре | Торак урын урнашу урынының почта адресы | Торак урынның төре, гомуми мәйданы, кв.метр | Файдалану нигезләре (социаль наем шартнамәсе яки милек хокукы нигезендә), шартнамә датасы һәм реквизитлары, милек хокукы турында таныклык реквизитлары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |

II. Милек хокукында минеке һәм (яки) минем гаилә әгъзаларымныкы булган торак урыннан баш тартуга китергән граждан-хокукый алыш-бирешләр (бу торак урыннан дәүләт милке яки муниципаль милек файдасына баш тартудан тыш) башкардым (башкармадым).
(кирәк булмаганын сызарга)

Милек хокукында минеке һәм (яки) минем гаилә әгъзаларымныкы булган торак урыннан баш тартуга китергән граждан-хокукый алыш-бирешләр (бу торак урыннан дәүләт милке яки муниципаль милек файдасына баш тартудан тыш):

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Торак урыннан баш тартуны башкарган затның сертификат алучы белән туганлык мөнәсәбәтләре | Торак урын урнашу урынының почта адресы | Торак урынның төре, гомуми мәйданы, кв.метр | Торак урыннан баш тартуга китергән граждан-хокукый алыш-бирешләр һәм әлеге алыш-бирешләр башкару фактын раслый торган документлар реквизитлары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |

Мин һәм минем гаилә әгъзалары әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын раслыйбыз. Федераль башкарма хакимият органнарында (Федераль салым хезмәтен, Федераль миграция хезмәтен, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтен кертеп) тапшырылган документларны тикшерүгә, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәбез.

Мин, ______________________________________________________________________________,
( фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) ,
үзем биргән мәгълүматларда һәм гаризага теркәгән документларда дөреслеккә туры килми торган һәм дәүләт торак сертификаты алу өчен нигез булган мәгълүматлар булуы ачыкланган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылу турында кисәтелдем.

Субсидия акчасыннан файдаланып, торак урын сатып алганнан соң торак шартларын яхшырту (торак урыннар алу) чиратыннан мине төшереп калдыруга риза.

Гаризага түбәндәге документларны терким:

1) ________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
2) ________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
3) ________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
4) ________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
5) ________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
6) ________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
7) ________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
8) ________________________________________________________________________.
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)

Сертификатны алу һәм аннан файдалану шартлары белән таныштым һәм аларны үтәргә вәгъдә бирәм.

________________________________________ ____________________ __________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы) (датасы)

Гаиләнең балигъ булмаган әгъзалары гариза белән риза:

1) ______________________________________________ ____________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
2) ______________________________________________ ____________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
3) ______________________________________________ ____________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
4) ______________________________________________ ____________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
5) ______________________________________________ ____________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
6) ______________________________________________ ____________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
7) ______________________________________________ ____________________.
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)

______________________________________________________________________
гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының имзасын раслый торган нотариаль язу)
______________________________________________________________________

«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә 9 нчы кушымта

Форма

Бирелгән дәүләт торак сертификатларын исәпкә алу кенәгәсе

______________________________________________________________

(җирле үзидарә органы исеме)

| Т/с | Сертификат | | | | Сертификат алучы турында мәгълүматлар | | | | | Документларны тикшергән һәм сертификат тапшырган затның имзасы | Сертификат хуҗасының имзасы, датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сериясе | номеры | бирү датасы | бирелә торган торак урынның гомуми мәйданы күләме, кв.метр | фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Россия Федерациясе гражданы паспорты | | | гаилә составы, кеше | | |
| | | | | | | номеры | бирү датасы | кем тарафыннан бирелгән | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

______________________________